**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күәм авыл җирлеге Дусым торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“19” ноябрь 2021 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенең Дусым торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Дусым авылы территориясендә 2022 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенең Дусым торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

- су башнясы сатып алу, урнаштыру (төзелеш материаллары сатып алу), хезмәтләр өчен түләү.
- бетон кольцолар сатып алып Г.Кутуй урамындагы коены ремонтлау, хезмәтләр өчен түләү.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенең Дусым авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Күәм авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Дусым авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күәм авыл җирлеге башлыгы Гатауллин Р.Р.